ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 декабрь, 2015 ел № 4/11

Шәһәр Советының 2012 елның 26 гыйнварендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты һәм аның бүлекләре карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия составларын раслау турында» 16/9 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының 2011 елның 20 маендагы «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр турында» 26-ЗРТ санлы Законы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2012 елның 26 гыйнварендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты һәм аның бүлекләре карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия составларын раслау турында» 16/9 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2012 елның 5 июлендәге 19/14, 2013 елның 30 маендагы 25/17, 2013 елның 30 октябрендәге 27/17, 2014 елның 17 апрелендәге 30/17, 2014 елның 10 июлендәге 31/21, 2015 елның 27 февралендәге 38/10, 2015 елның 15 апрелендәге 39/20 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия составына кертергә:

- Аюпова Фирдүсә Фәнәвис кызын – Шәһәр Советы депутатын, «М. Вахитов исемендәге 2 нче гимназия» МБББУ директорын.

- Әсәтова Лилия Илдус кызын – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

комиссия составыннан чыгарырга:

- Бариева Гөлнара Айрат кызын;

- Борһанова Айгөл Әбүзәр кызын.

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Комсомол районы хакимияте карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия бүлеге составына кертергә:

- Рогожников Сергей Валентиновичны – ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының «Республика наркология диспансеры» ДАССУ филиалы – «Яр Чаллы наркология диспансеры»ның диспансер бүлеге үсмерләр кабинеты фельдшер - наркологын (килешү буенча);

- Нургалиева Гөлнар Шамил кызын – Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлеге баш белгечен;

комиссия бүлеге составыннан чыгарырга:

- Кубарева Лариса Геннадьевнаны.

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Автозавод районы хакимияте карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия бүлеге составына кертергә:

- Николаева Надежда Григорьевнаны – Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге баш белгечен;

комиссия бүлеге составыннан чыгарырга:

- Мифтахова Эльмира Зөфәр кызын.

4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Үзәк районы хакимияте карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия бүлеге составына кертергә:

- Абдалова Илзирә Мәүлиҗан кызын – Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлегенең әйдәүче белгечен;

комиссия бүлеге составыннан чыгарырга:

- Иманова Любовь Винидимовнаны.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев